**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

03.07.2023 № 222

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалар идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимы кертү турында**

Авыл хуҗалыгы культураларының коруына китергән авыл хуҗалыгы өчен хәвефле һава торышы күренешләре (кырау, коры җил, туфрактагы корылык) нәтиҗәсендә азык-төлек ягыннан иминлеккә янаган куркынычны бетерү максатларында, «Халыкны һәм территорияләрне табигать һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

1. Татарстан Республикасының Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Апас, Арча, Әтнә, Баулы, Балтач, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Спас, Тәтеш, Тукай, Теләче, Чирмешән, Чистай һәм Ютазы муниципаль районнарының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалар идарә органнары һәм көчләре өчен, махсус боерык чыкканга кадәр, 2023 елның 3 июленнән гадәттән тыш хәл режимы кертергә һәм төбәк дәрәҗәсендә чаралар күрелергә тиешлеген билгеләргә.

2. Әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы муниципаль районнары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

гадәттән тыш хәл режимы кертелү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка мәгълүмат җиткерүне тәэмин итәргә;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссияләр һәм хәвефле табигать күренешләренең тискәре нәтиҗәләрен юкка чыгару һәм аварияләрдән соң торгызу эшләре алып бару буенча чаралар уздыруга җәлеп ителүче көчләрнең эш төркемнәре составын билгеләргә;

биш көн эчендә гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлтелгән чаралар эшләргә.

3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына биш көн эчендә гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар эшләргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН